# Зилә ничек киенгән

(Татьяна Холкинадан Sabyem.ru тәрҗемәсе)

Беркөнне иртән Зиләнең әнисе:

- Зилә, кызым, әйдә урамга чыгабыз, - дип чакырган.

Зилә урамда йөрергә бик яраткан, ләкин киенергә яратмаган.

- Әни, киендер мине, минем кулларым кечкенә, алар киенә белмиләр, - дип үтенгән ул.

- Син үзең зур, ә кулларың кечкенә? – дип гаҗәпләнгән әнисе. - Менә сиңа чалбар, менә оекбаш, менә свитер һәм ботинкалар – үзең киен! Ә минем вакытым юк!

Ә Зилә бүлмә буйлап ничек йөргән, шулай йөргән дә йөргән.

- Зилә, киен, урамга чыгабыз, - дип тагын эндәшеп караган әнисе.

- Булдыра алмыйм, - дип зарланган Зилә.

Зиләнең куллары аңа үпкәләгәннәр һәм тиз-тиз генә киенә дә башлаганнар! Шулай итеп ашыгып, барлык киемнәрне бутап бетергәннәр. Чалбарны башка кидергәннәр, чалбар урынында – свитер; оекбаш һәм ботинкалар – кулларда, бияләйләр аякларда. Билбау урынында - шарф. Ә башлыкны җиңдә онытып калдырганнар.

Әнисе аңардан көлә башлаган. Зилә үз-үзенә көзгедән караган да оялган - ничек инде ул шундый кыяфәттә урамга чыксын? Ул өстеннән киемнәрен тиз генә салган да, дөрес итеп киеп куйган. Киенүе шулхәтле тиз һәм пөхтә булган, хәтта үзе дә шаккаткан – булдыра ала икән!

Бирем: рәсемне буя һәм курчакны киендер.

